РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**19.10.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№24/2**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2016 елның 10 ноябрендәге «Җир салымы ставкаларын билгеләү, түләү тәртибен гамәлгә кертү турында» 9/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 113 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 33 статьясы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2016 елның 10 ноябрендәге «Җир салымы ставкаларын билгеләү, түләү тәртибен гамәлгә кертү турында»гы 9/1 номерлы (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 2017 елның 07 августындагы 16/3 номерлы, 27.06.2018 елның 27 июнендәге 26/3 номерлы, 2018 елның 23 ноябрендәге 29/2 номерлы, 2019 елның 07 октябрендәге 39/3 номерлы, 2019 елның 23 октябрендәге 40/2 номерлы, 2021 елның 28 апрелендәге 7/3 номерлы, 2021 елның 22 октябрендәге 10/3 номерлы карарлары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасының 3 абзацында «һәм объектлары» сүзләрен «һәм (яисә) объектлар» сүзләренә алмаштырырга, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлеш» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлеше» сүзләренә, «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Чистопольские известия» газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru),

шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatar.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар җир салымы түләүгә һәм җир салымы буенча аванс түләүләре түләүгә бәйле рәвештә 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач кына үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы М.И. Ксенофонтов